| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
| --- | --- | --- |
| СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

21 октябрь 2022 ел № 25

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2018нче елның 26нчы апрелендә кабул ителгән 14нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 №881 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

Карар итте:

1. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 26.04.2018 ел, №14 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» гә таянып, Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгының, аның урынбасарының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»не 26.04.2018 №14 карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен арттырырга.

3. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфа окладлы күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 26.04.2018 №14 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. 2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа окладын 11 958 сум күләмендә расларга.»;

4.2. 1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар өчен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2022 елның 1 октябреннән гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

6. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Саба шәһәр җирлеге Советының
2022 елның 21 октябре, № 25 карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Шәһәр җирлеге башлыгы | 19 498 |
| Шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары | 14 527 |
| Депутатлар | 11 958 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11 958 |